ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**22.07.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1482**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында 2016-2020 елларга Наркотикларга каршы программага үзгәрешләр кертү турында

«2014-2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш «дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 октябрендәге 764 номерлы Карарын үтәү йөзеннән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 апрелендә 1082нче номерлы карары белән расланган 2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында Наркотикларга каршы программага әлеге карарның кушымтасына ярашлы үзгәрешләр кертергә.
2. ЯҮМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге җитәкчесе Д.С. Анисимовка әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче Д.А. Сапожников

1нче кушымта
Зеленодольск муниципаль
районы Башкарма комитеты
карарына
22.07.2019 № 1482

**Программаның паспортында «Күләме һәм финанслау чыганаклары» пунктының 7 нче графасын түбәндәге эчтәлекле текст белән тулыландырырга:** «Әлеге программаны гамәлгә ашыруга бәйле чараларны финанслау Зеленодольск муниципаль районы бюджетында расланган ассигнованиеләр чикләрендә тиешле финанс елына гамәлгә ашырыла. Программаны тормышка ашыруга тотылган акчаларның күләме район бюджеты, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә инфляция процесслары һәм икътисадый вәзгыять мөмкинлекләреннән чыгып төгәлләштерелергә һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин».